**7 сыйныф.**

**Җаваплар** **50 балл**

**I бүлек**

Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләр янына авторларын язып чыгыгыз

1. “Эшкә өндәү” шигыре ___Г.Тукай________________ **1әр балл**
2. “Татар байрагы” шигыре __М. Гафури_______________
3. “Яз башы” хикәясе _Г.Ибраһимов_____________
4. “Сагыну” нәсере _Г.Кутуй___________________
5. “Кем җырлады” хикәясе _Ә.Еники________________

**II бүлек**

Мәсәл жанрына хас үзенчәлекләрне атагыз. Мисал яки мисаллар ярдәмендә фикерләрегезне дәлилләгез.

**8 балл**

Мәсәл — әдәбиятның борынгы һәм үзенчәлекле жанрларыннан берсе. Ул — гадәттә шигырь белән языла торган кечкенә күләмле эпик әсәр. Аның геройлары рәвешендә хайваннар алына һәм алар образы аша кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр чагылдырыла.

Мәсәлнең финалы гадәттә әсәрнең төп идеясе ачылуы белән тәмамлана./ Мәҗит Гафури — татар әдәбиятында мәсәл жанрына актив мөрәҗәгать иткән әдипләрнең берсе.

**III бүлек**

Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез

а) 1. Г.Тукай, “Туган авыл” **1 балл**
*2. Аулыбызның ямен, суы тәмен беләм,* **1 балл**
*Шуңа күрә сөям җаным, тәнем белән.* **1 балл**
3. Туган авылны ярату хисе 3 **балл**
б) 1. М.Гафури, "Татар байрагы” **1 балл**
2. *Түздек, чыдадык,* **1 балл**
*Һаман үлмәдек* **1 балл**
3. Шигырь татар милләтенең батырлыгы белән горурлану хисе **3 балл**

Дуслык турында нинди мәкаль-әйтемнәр беләсез. 10 мисал языгыз

**10 балл**

**IV бүлек**

Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез

1 Г.Кутуй **1 балл**
2 Нәсер **1 балл**
3 “Сагындым, бик сагындым сине, туган ил!” җөмләсенең нигә еш кабатлануын аңлатыгыз. **3 балл**

Әлеге сүзләргә бәйләп, туган ягыгызны ярату хисләре турында бер бит күләмендә инша языгыз. **10 балл**

**45 балл**

**8 сыйныф**

**I бүлек**

Түбәндә тәкъдим ителгән әсәрләр янына авторларын язып чыгыгыз

**5 балл**

1. “Туган ягым – яшел бишек” повесте Г.Бәширов_________**1әр балл**
2. “Катыйльгә” шигыре М.Җәлил__________________
3. “Сөннәтче бабай” повесте Г.Исхакый________________
4. “Беренче театр” комедиясе Г.Камал__________________
5. “Ак чәчәкләр” романы Г.Әпсәләмов_______________

**II бүлек**

Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез

1. М.Җәлил “Бер үгет” **1 балл**
2. Шигырьдәге төп хисне билгеләгез 4 **балл**
3. Шигырьдә кулланылган тропларны күрсәтегез
(чагыштыру, метафора, гипербола, аллегория һ.б.) **10 балл**

**III бүлек**

**10 балл**

Повесть жанрына хас үзенчәлекләрне атагыз. Мисал яки мисаллар ярдәмендә фикерләрегезне дәлилләгез.

ПОВЕСТЬ - төп герой тормышындагы берничә охшаш вакыйганы сурәтләгән, берничә сюжет сызыгын бер үзәккә туплаган эпик жанр. А.Гыйләҗев «Җомга көн кич белән», «Әтәч менгән читәнгә», М. Юныс «Биектә калу»

**15 балл**

**IV бүлек**

Яраткан язучыгызның иҗат портретын һәм иҗат лабораториясен тудырыгыз. IV бүлек биременә җавапны күрсәтелгән юнәлеш буенча бер битлек итеп, инша рәвешендә языгыз

1. Әдип яшәгән чор
2. Әдәбиятка алып килгән яңалыгы
3. Әсәрнең (әсәрләрнең) жанры, күтәрелгән төп идея-фикерләр
4. Сез өйрәнгән әсәрдә (әсәрләрдә) автор иҗатына гына хас милли үзенчәлекләр

**ҖАВАП 45 балл**

**9 сыйныф**

**I бүлек**

**1әр балл**

1.“Үлемнән көчлерәк” (Самат Шакир) әсәренең жанры – Очерк -

2. “Җомга көн – кич белән” әсәрен иҗат иткән язучы – А. Гыйләҗев_

3. Проза төренең жанрларын билгеләп, дөрес җавапны түгәрәккә алыгыз:

а) шигырь, хикәя, драма ә) трагедия, комедия, драма

**б) роман, повесть, хикәя** в) әкият, табышмак, җыр

**II бүлек**

Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез

1. Энҗе Мөэминова, “Икмәк” **1 балл**

2. Шигырьдәге төп хисне билгеләгез **3 балл**

4. Шигырьдә образ, хис тудыруда ярдәм иткән троплар, стилистик, лексик чараларны табыгыз **10 балл**

**III бүлек**

Хикәя жанрына хас үзенчәлекләрне атагыз. Мисал яки мисаллар ярдәмендә фикерләрегезне дәлилләгез.

ХИКӘЯ - бер яки берничә вакыйганы эченә алган, кеше характерының бер сыйфаты, үсү-үзгәрүе хакында сөйләүче эпик жанр. Ә.Еники *«Әйтелмәгән васыять».* **8 балл**

**IV бүлек**

**IV** бүлек биремнәренә җавап язганчы, биремнең номерын күрсәтегез

1 Ф. Яруллин, "Җилкәннәр җилдә сынала" **1 балл**

2 Повесть **1 балл**

3 Батырлык” сүзе үз эченә нинди сыйфатларны ала? Санагыз
- тәвәккәллек – кыюлык – түземлелек - югалып калмау - ихтыяр көче булу - һәрвакыт ярдәм итә алу һ.б. 3 **балл**

4. “Батырлык” сүзенә бәйләп, троплар кулланып, кыска инша языгыз **15 балл**

**ҖАВАП 47 балл**

**10 сыйныф**

**I бүлек**

| Бирелгән сорауларга дөрес җавапларны күрсәтегез |
|---|

**1әр балл**

1. Болгар чорында иҗат иткән язучы:

**а) Кол Гали** ә) Сәйф Сараи
б) Фатих Кәрими в) Мәүлә Колый

**2.** Ничәнче елдан болгарларда, рәсми рәвештә, ислам дине гамәлгә кертелә:

а) 737
**б) 922**
в) 911

**3.** Ислам дине белән бергә төркиләргә үтеп кергән һәм иң озак кулланышта булган графика:

**а) гарәп графикасы**
ә) уйгур графикасы
б) рун алфавиты

**II бүлек**

| Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез |
|---|

1. ХАИ "Идегәй", дастан **2 балл**
2. Төп геройларны санап чыгыгыз **2 балл**
3. Әсәр турында белгәннәрегезне языгыз **10 балл**

**III бүлек**

| Г.Исхакый иҗатына бәйле сорау-биремнәргә җавап бирегез |
|---|

1. 5 балл
2. 5 балл
3. 5 балл

**IV бүлек**

| IV бүлек биремнәренә җавап язганчы, биремнең номерын күрсәтегез |
|---|

1. К.Насыйри. "Тәрбия китабы" ("Китаб-эт тәрбия") **1 балл**
2. "Мәгърифәтче галим" – аң-белем алырга өндәүче галим. Аңлатыгыз. **4 балл**

"Тәрбия", "белем" төшенчәләрен кулланып, троплар, стилистик чаралардан да файдаланып, бер бит күләмендә инша языгыз. **10 балл**

**11 сыйныф**
**ҖАВАП 60 балл**

**I бүлек**

Бирелгән сорауларга дөрес җавапларны күрсәтегез

**1әр балл**

1. **“Мәхәббәт тәүбәсе” (Һ.Такташ) әсәренең жанры:**
   ә) поэма
2. **Бөек Ватан сугышында һәлак булган язучы:**
   б) Фатих Кәрим
3. **Фатих Кәримнеке булмаган әсәр:**
   в) Кошчык

## II бүлек

Роман жанрына хас үзенчәлекләрне атагыз. Мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз

**10 балл**

**РОМАН** — аерым кешеләрнең язмышын һәм тирәлек белән бәрелешен сурәтләүче, шуның белән янәшәдә җәмгыятькә бәя бирелә торган күләмле эпик жанр. Н. Фәттах *«Итил суы ака торур»*

## III бүлек

М.Мәһдиев иҗаты белән бәйле сорау-биремнәргә җавап языгыз

1. **4 балл**
2. **4 балл**
3. **4 балл**
4. **4 балл**
5. **4 балл**

Түбәндә тәкъдим ителгән юлларны укыгыз һәм биремнәргә җавап бирегез

1. **1 балл//** “Сүнгән йолдызлар” (К.Тинчурин)
2. **5 балл**// Төшне Исмәгыйль күрә. Сюжет сызыгында төш күрү вакыйгасы үзәк урынны тота. Төп фикер сугыш темасы белән бәйләнә.
3. **4 балл** //Сәрвәр, Исмәгыйльгә хас сыйфатларны санагыз һәм шуңа бәйләп төп идеяне ачыклагыз.

## IV бүлек

**IV** бүлек биремнәренә җавап

**5 балл**

Юк ромашка,
*Минем йөрәкнең*
*Януларын баса алмыйсың*

Бу өзектә лирик геройның эчке кичерешләре тасвирлана һәм сөю, мәхәббәт хисен сурәтләгәндә әзер тотрыклы метафора кулланыла.

## V бүлек

11 сыйныфта укыган әсәрләрдән мисаллар китереп, ике яшь кеше арасындагы мәхәббәт хакында фикерләрегезне инша итеп языгыз

**12 балл**